**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгару турында**

КАРАР № 11

Ютазы ав. 14 июль 2022 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгару турында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 294-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 27 июлендәге «Тикшерү кәгазьләрен әзерләү, карап тотуга, иҗтимагый фикер алышуга таләпләрне раслау, тикшерү кәгазьләрен раслау, куллану, актуальләштерү рәвешләрен, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларын раслау турында» 1844 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2019 елның 17 июлендәге «Ютазы муниципаль районы Советының 10 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Ютазы муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2012 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль мәсьәләләр исемлеге) формасын раслау турында»гы 4 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов